**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 4 октябрь № 714

г. Казань

2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантларны гамәлгә куярга.

2. 2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 октябрь, 714 нче карары белән расланды

**2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү тәртибен билгели.

1.2. Бу Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Грантлар – субсидияләр рәвешендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;

Грант бирүче – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

Вәкаләтле учреждение – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе;

Конкурс – грантлар бирү өчен конкурста катнашучыларны сайлап алуга бәйле чара;

Конкурста катнашучылар – фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәр һәм укытучылар;

конкурс комиссиясе – конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен вәкаләтле учреждение тарафыннан төзелгән комиссия;

Грант алучылар – конкурста җиңүчеләр дип танылган һәм вәкаләтле учреждение белән грант бирү турында килешү төзегән конкурс катнашучылары;

галим – «фәннәр кандидаты» һәм (яки) «фәннәр докторы» гыйльми дәрәҗәсе бирелгән югары белем бирә торган мәгариф оешмасы яки һөнәри белем бирү оешмасы хезмәткәре, шулай ук өченче елын укый торган аспирант.

1.3. Грантлар бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) чараларын тормышка ашыруга 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Грантлар бирүнең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм

укытучыларга ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасында фән һәм мәгариф теле буларак татар телен саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру.

1.5. Дәүләт программасы нигезендә, әлеге максатларга бирелә торган акча чикләрендә, һәр алты Грантның күләме 200 000 (ике йөз мең) сум тәшкил итә.

1.6. Грант алучылар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

1.7. Үз эченә конкурс комиссиясе рәисен, рәисе урынбасарын, секретарен һәм әгъзаларын алган конкурс комиссиясенең сан ягыннан һәм шәхси составы Вәкаләтле учреждение президиумы тарафыннан раслана. Конкурс комиссиясе эшчәнлеге иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

## 2. Конкурста катнашу хокукы

2.1. Конкурста катнашуга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан фәнни оешмаларда яки мәгариф оешмаларында фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәр һәм укытучылар кертелә.

2.2.Конкурска монографияләр, мәкаләләр циклы (кимендә 7 мәкалә), методикалар һәм технологияләр эшләү яки булдыру материаллары, яңа фәнни-техник продукция рәвешендә башкарыла торган һәм татар телендә язылган фәнни проектлар (алга таба – Проект) тапшырыла.

2.3. Конкурс түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

татар теле, әдәбияты, фольклор һәм сәнгать;

Татарстан һәм татар халкы тарихы;

төбәк мәгариф проблемалары;

медицина, биология, экология, авыл хуҗалыгы фәннәре;

математика, физика, химия, геология һәм география;

машина төзелеше проблемалары һәм төзелеш технологияләре, мәгълүмат технологияләре.

2.4. Элегрәк рус телендә яки башка телләрдә эшләнгән һәм аннары татар теленә тәрҗемә ителгән проектлар Конкурста катнашуга кертелми.

## 3. Конкурсны үткәрү тәртибе

3.1. Конкурсны үткәрү шартлары һәм вакытлары турындагы мәгълүмат Вәкаләтле учреждениенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Сайт) конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурс үткәрү турындагы карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә урнаштырыла.

3.2. Конкурста катнашу өчен түбәндәге документлар тапшырыла:

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча заявка;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча Проектның тасвирламасы;

Проектның тулы исемен, авторның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (булганда), әлеге Нигезләмәнең 2.3 нче пункты нигезендә Конкурс юнәлешен

күрсәтеп, Проектка аннотация;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан фәнни оешма яки мәгариф оешмасы, аларның филиаллары, фәнни яки мәгариф бүлекчәләре җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә имзаланган һәм таныкланган Проектка тәкъдимнамә. Тәкъдимнамә Проектның тулы исемен; авторның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (булганда) һәм аның фәнгә керткән өлешен, Татарстан Республикасының фән яки мәгариф өлкәсе өчен Проектның әһәмияте турындагы мәгълүматны үз эченә алырга тиеш;

авторның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (булганда), эш урынын, биләгән вазыйфасын, гыйльми дәрәҗәсен, туган көнен, өй һәм эш адресын, өй һәм эш телефоннары номерларын, E-mail, автор катнашында басылып чыккан фәнни эшләр, монографияләр, фәнни конференцияләрдәге чыгышлар исемлеген, автор катнашында алынган грантлар, премияләр санын һәм исемен үз эченә алган Проект авторы хакында белешмәләр;

тапшырылган документлар исемлеге.

3.3. Документлар рус телендә ике нөсхәдә кәгазьдә һәм электрон чыганакта рәсмиләштерелә һәм Вәкаләтле учреждениегә, «Фәнни-оештыру бүлегенә» дип билгеләп, 420111, Казан шәһәре, Бауман урамы, 20 нче йорт адресы буенча җибәрелә.

3.4. Документларны кабул итү, Конкурс үткәрү турындагы мәгълүмат Сайтта урнаштырылган көннән соң, эш көннәрендә 20 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5. Заявкалар һәм аңа теркәлә торган документлар түләүсез нигезендә тапшырыла һәм кире кайтарылмый.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2 нче пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү һәм теркәү алар тапшырылган көнне Вәкаләтле учреждение тарафыннан башкарыла.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.2 нче пунктында күрсәтелгән документлар, аларны тапшыру вакыты тәмамланганнан көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә үткәрелә торган конкурс комиссиясе утырышында карап тикшерелә.

3.8. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.2 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы күләмдә тапшырмау;

б) кертелгән документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

в) документларны Конкурска тапшыру вакыты тәмамланганнан соң кертү;

г) 3.2 нче пунктта күрсәтелгән документларда һәм заявкадагы мәгълүматларның дөрес булмавын ачыклау;

д) әлеге Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү.

е) Проектларның әлеге Нигезләмәнең 2.2 һәм 2.4 нче пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

3.9. Конкурска кертелгән затлар һәм Конкурста катнашуга кертелмәгән затлар исемлекләре конкурс комиссиясе утырышын үткәргән көннән соң бер эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Конкурс

комиссиясе утырышы беркетмәсе эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Сайтка урнаштырыла.

3.10. Конкурста катнашуга кертелмәгән затларга конкурс комиссиясе беркетмәсен раслаган көннән соң өч көн эчендә өстәмә рәвештә хәбәрнамәләр җибәрелә.

3.11 Конкурста катнашуга кертелгән затларның заявкалары, конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен рәсмиләштергәннән соң, өч көн эчендә конкурс комиссиясе әгъзаларына асылын карап тикшерү өчен җибәрелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары, аларга заявкаларны тапшырган көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявкаларны, аларга теркәлгән документларны карап тикшерә һәм бәяләү кәгазьләрен Вәкаләтле учреждениесенең фәнни-оештыру бүлегенә кертә.

3.12. Конкурста катнашучыларның проектлары әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү йомгаклары буенча, бәяләү кәгазьләрен тапшырган көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә рейтинг төзелә.

Конкурста җиңүчеләрне сайлап алу конкурс комиссиясе утырышында рейтинг төзегәннән соң гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда конкурс комиссиясе әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы санала. Утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, конкурс комиссиясе карары кабул ителгән булып санала. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була. Рәис конкурс комиссиясе утырышында катнашмаса, аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

3.13. Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый торган конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе, конкурс комиссиясе утырышын үткәргән көннән соң, бер эш көне эчендә рәсмиләштерелә, конкурс комиссисе рәисе яисә утырышта рәислек иткән урынбасары һәм конкурс комиссиясенең җаваплы секретаре тарафыннан имзалана.

3.14. Конкурс йомгаклары турындагы мәгълүмат җиңүчеләр исемлеген раслаган көннән соң өч көн эчендә Сайтка урнаштырыла.

## 4. Грантлар бирү тәртибе

4.1. Конкурс комиссиянең Грантлар бирү турындагы карары Вәкаләтле учреждение һәм Грант алучы арасында килешү (алга таба – Килешү) төзү өчен нигез булып тора.

4.2. Килешү Конкурс йомгаклары турындагы мәгълүмат Сайтка урнаштырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә төзелә.

4.3. Килешү формасы Вәкаләтле учреждение тарафыннан раслана.

4.4. Килешүдә Грантның күләме, максатчан билгеләнеше, хисап финанс елында файдаланылмый калган Грантны Грант алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, Гранттан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе, Грант алучының Грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен

үтәвенә Вәкаләтле учреждение һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә Грант алучының ризалыгы күздә тотыла.

4.5. Вәкаләтле учреждение Килешү төзегәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Грантны Грант алучының хисап счетына күчерә.

4.6. Грант алучы Вәкаләтле учреждение раслаган форма буенча һәм Килешүдә каралган тәртиптә Гранттан файдалану турындагы хисапны Вәкаләтле учреждениегә тапшыра.

4.7. Грантларга лаек булган Проектларның төп нәтиҗәләре Вәкаләтле учреждение тарафыннан «Фәнни Татарстан» журналында бастырыла.

4.8. Грантлар алган Проектлар Вәкаләтле учреждениенең китапханәсенә саклауга тапшырыла.

## 5. Грант алучының җаваплылыгы

5.1. Грант алучы Вәкаләтле учреждениегә тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап тота.

5.2. Грант Вәкаләтле учреждениенең тиешле таләбен алган көннән соң 30 көн эчендә Грант алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтырылырга тиеш:

а) Грант алучының Грантны бирү шартларын үтәмәве;

б) Гранттан максатка ярашсыз файдалану.

5.3. Грант алучы Грантны кайтару вакытын бозган очракта, Вәкаләтле учреждение бу Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында билгеләнгән вакыт чыкканнан соң җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

5.4. Хисап финанс елында файдаланылмый калган Грант, Килешүдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш. Грант алучы хисап финанс елында файдаланылмый калган Грантны кайтару вакытын бозган очракта, Вәкаләтле учреждение 15 көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

5.5. Вәкаләтле учреждение һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Грантны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә законнар нигезендә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыра.

5.6. Гранттан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту законнар нигезендә Вәкаләтле учреждение тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушыма

Форма

2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар алуга конкурста катнашуга
заявка

1. Гариза бирүче эшли торган оешма:

| |
|---|
| |
| тулы һәм кыскартылган исемен, ИНН, юридик адресын, телефонын, e-mail күрсәтергә |
| |
| |

2. Оешма җитәкчесе:
Ф.И.Ат.ис.: ______________________________
Вазыйфасы: ______________________________
Эш тел.: ______________________________

3. Гариза бирүче:
Ф.И.Ат.ис.: ______________________________
Туган көне: ______________________________
Вазыйфасы: ______________________________
Тел.: ______________________________

4. Сезнең кайчан да булса дәүләт гранты яки муниципаль грант алганыгыз булдымы? Әгәр булса, елын, проектның исемен һәм грантның суммасын күрсәтегез:

| |
|---|
| |
| |
| |
| |

5. Фәнни проект турында мәгълүмат:
Исеме: ______________________________
Юнәлеше:[1] ______________________________

[1] Нигезләмәнең 2.3 нче пунктында күрсәтелгәннәрдән.

6. Проектның кыскача тасвирламасы (проектның төп бүлекләре эчтәлеген кыскача бәян итү):

| |
|---|
| |
| |
| |
| |
| |
| |
| |

7. Түләү реквизитлары:
Банкның исеме, ИНН, КПП:______________________________________________

______________________________________________

хисап счет (р/с): ______________________________________________
кор.сч. ______________________________________________
БИК: ______________________________________________

Әлеге анкета белән заявкада китерелгән бөтен мәгълүматның, шулай ук өстәмә материалларның төгәл һәм дөрес булуын белдерәм һәм вәкаләтле операторга эш урыны буенча һәм дәүләт хакимияте вә муниципаль хакимият органнарыннан кертелгән белешмәләрне тәгаенли торган мәгълүмат соратып алырга ризалыгымны бирәм.

Гариза бирүченең Ф.И.Ат.ис. _________________________ / ____________ /
(имза)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы килмим.

Гариза бирүченең Ф.И.Ат.ис. _________________________ / ____________
(имза)

Гариза бирүче имзасы:
____________________________________________________________ раслыйм.

| ________________ | ________________ | ________________ | |
|---|---|---|---|
| Гариза бирүче эшли торган оешманың кадрлар бүлеге хезмәткәре яки башка вәкаләтле затның вазыйфасы | МУ | имза | И.Ат.ис. Фамилия |

2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

Фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар алуга конкурста катнашуга проект тасвирламасы
(5 биттән артык түгел)

1. Проектны тормышка ашыра башлаганда хәлнең гомуми тасвирламасы (1 биттән артык түгел):

| |
|---|
| |

2. Проектның максатлары һәм бурычлары:

| |
|---|
| |

3. Чаралар планы (төп чаралар тасвирламасы, проектны тормышка ашыру этаплары һәм вакытлары):

| Т/с | Тормышка ашыру этабы | Чаралар исеме | Тормышка ашыру вакытлары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

4. Проектның кирәкле булуын нигезләү:

| |
|---|
| |

5. Проект бюджеты (күздә тотылган кертемнәр һәм планлаштырылган чыгымнар сметасы, аны нигезләү):

Чыгымнарның гомуми суммасы (сум):

(сумнарда)

| Т/с | Чыгымнар исеме | Шәхси акча | Таләп ителә торган акча | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| Барлыгы | | | | |

6. Проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең мәгънәләре:

| Т/с | Нәтиҗәлелек күрсәткече | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Кушымталар CD, DVD-мәгълүмат саклау җайланмаларында, электрон рәвештә һәм бастырып чыгарылып (видеоматериаллар, фотографияләр, басма продукция һ.б.) кертелә.

Гариза бирүченең Ф.И.Ат.ис. ______________________/______________________ /
(имза)

2016 елда фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары

| Т/с | Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары | Бәяләмә (баллар) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Икътисадый нәтиҗәлелек критерийлары | |
| 1.1. | Проектны тормышка ашыру өчен планлаштырылган чыгымнар һәм аның көтелә торган нәтиҗәләре чагыштырмасы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 1.2. | Проектны тормышка ашыруга чыгымнарның нигезләнгән булуы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 2. | Социаль нәтиҗәлелек критерийлары | |
| 2.1. | Проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булу, аларның проект бурычларына туры килүе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 2.2. | Планлаштырылган чараларның проектны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләргә туры килүе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 3. | Өстәмә критерийлар | |
| 3.1. | Гариза бирүченең проектны тормышка ашыру өчен кирәкле һөнәри һәм фәнни тәҗрибәсе булу | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| | БАРЛЫГЫ | 50 баллга кадәр |